ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш), № 47 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $2^1$ статьяның 2 өлешендә:
а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында карар кабул итү һәм территорияне планлаштыру документларын раслау;»;
б) түбәндәге эчтәлекле $10^{13} – 10^{17}$ пунктлар өстәргә:
«$10^{13}$) җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары проектларын, җирлекләрнең генераль планнарына, шәһәр округларының генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тотучы проектларны җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәрмичә генә әзерләү очракларын билгеләү;
$10^{14}$) җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектларын, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертүне күздә

тотучы проектларны җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәрмичә генә әзерләү очракларын билгеләү;

$10^{15}$) җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне планлаштыру проектларын һәм территорияне ызанлау проектларын раслау турында карар кабул ителә торган мондый проектларны, территорияне планлаштыруның һәм территорияне ызанлауның мондый проектларына үзгәрешләр кертүне җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәрмичә генә раслау очракларын билгеләү;

$10^{16}$) территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенә карата, территорияне комплекслы үстерү хакындагы шартнамә нигезендә расланган территорияне планлаштыру документлары булмаганда, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү рөхсәт ителә торган очракларны билгеләү;

$10^{17}$) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 65 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты һәм 8 өлешенең 3 пункты нигезендә блоклы төзелгән йортлар һәм индивидуаль торак төзелеше объектлары тузуның югары дәрәҗәсен, аларның техник торышының тиешле дәрәҗәдә булмавын, мондый йортларда һәм объектларда инженер-техник тәэмин итү системаларының булмавын характерлый торган критерийларны билгеләү;»;

2) 10 статьяда:

а) $2^1$ өлештә «Территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру өчен генераль планга үзгәрешләр кертү таләп ителгән очракта,» сүзләрен «Территорияне комплекслы үстерү максатларында генераль планга үзгәрешләр кертү таләп ителгән очракта,» сүзләренә алмаштырырга;

б) 9 өлештә «Генераль планны» сүзләре алдыннан «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

3) 17 статьяның 2 өлешендә:

а) 1 пунктта:

«а» пунктчасына «(алар билгеләнгән, үзгәргән очракта)» сүзләрен өстәргә;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) планлаштырылучы структураның гамәлдәге (булганда) һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре (планлаштырылучы структураның бер яисә берничә элементы аерып алынган, планлаштырылучы структураның бер яисә берничә гамәлдәге элементы үзгәргән очракта);»;

б) 2 пунктта «гражданнарның» сүзен «кешенең» сүзенә алмаштырырга;

в) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) түбәндәгеләрне гамәлгә ашыруның этаплары һәм максималь сроклары булган территорияне планлаштырып үстерү чиратлылыгы турындагы нигезләмәләрне:

а) торак, җитештерү билгеләнешендәге, иҗтимагый-эшлекле һәм башка билгеләнештәге капиталь төзелеш объектларын, мондый объектларның эшләве өчен һәм кешенең яшәешен тәэмин итү өчен кирәкле коммуналь инфраструктура,

транспорт инфраструктурасы, социаль инфраструктура объектларын, башка объектларны (шул исәптән янгынга каршы көрәш деполары биналарын) архитектура-төзелеш проектлавын, төзүне, реконструкцияләүне;

б) капиталь төзелеш объектларын сүтүне (башка капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү өчен капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтәргә кирәк булган очракта).».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ — АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2025 ел, 10 апрель
№ 22-ТРЗ